| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>БОЛЬШЕПОДБЕРЕЗИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ ПОДБЕРЕЗЬЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 елның 10 нчы октябере Олы Подберезье авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Кече Подберезье авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Уставының 22статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

2019 елның 21 октябрендә 14 сәгать 00 минутта Кече Подберезье авылы, Зур Кызыл урамы, 14Б адресы буенча урнашкан авыл клубы бинасында ТР, Кайбыч районы, , Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Кече Подберезье торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

1. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Олы Подберезье авыл җирлеге Кече Подберезье авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

а) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- материаллар сатып алып, юлларны норматив хәлгә китерү;
- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*б) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту;*

- материаллар сатып алып зиратларны чистарту һәм ремонтлау.

« РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Олы Подберезье авыл җирлеге башлыгы Ф.А. Чекмарев